Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

КАРАР

2024 елның 12 сентябре № 47/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 24 сентябрендәге 66/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлеге Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 66/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез мөлкәтне читләштерү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
3.1 пунктның 1 пунктчасында «ике ел» сүзләрен «бер ел» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Татар Баганалысы авыл җирлеге
Башлыгы Р.Р. Җәббаров